ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 132 от 29 октября 2018 г.

Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләренең һәм аның вазифаи затларының норматив булмаган хокук актларын гамәлсез , карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмау) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән суд карарлары, арбитраж суд карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау хакында

“Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ санлы Федераль законының 14 маддәсенең 1, 4 бүлекләре, 15 маддәсенең 1 бүлеге, “Коррупциягә каршы тору турында”гы 2008 ел, 25 декабрь, 273-ФЗ Федераль законының 6 маддәсенең 2.1. пункты, Татарстан Республикасында коррупциягә каршы эшне координацияләү буенча комиссия утырышының 07.06.2018 ел, ПР – 142 нче санлы протоколы нигезендә к а р а р б и р ә м :

1. Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләренең һәм аның вазифаи затларының норматив булмаган хокук актларын гамәлсез, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмау) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән суд карарлары, арбитраж суд карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау Тәртибен расларга (кушымта №1) .

2. Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарының, һәм аның вазифаи затларының норматив булмаган хокук актларын гамәлсез , карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмау) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән суд карарлары, арбитраж суд карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау буенча эшче төркем төзергә һәм аның составын расларга (кушымта №2).

3. Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2018 ел, 14 сентябрь, 110 нчы санлы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе В.Н Фәизовка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.П.Иванов

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгының
29.10.2018 ел, 132 санлы
карарына кушымта №1

## Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләренең һәм аның вазифаи затларының норматив булмаган хокук актларын гамәлсез , карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмау) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән суд карарлары, арбитраж суд карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау Тәртибе

### . I. Гомуми нигезләмә

1.1. Мамадыш муниципаль җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләренең һәм аның вазифаи затларының норматив булмаган хокук актларын гамәлсез, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмау) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән суд карарлары, арбитраж суд карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау процедурасын билгели (алга таба - Тәртип, хокук куллану практикасы мәсьәләләре), шулай ук Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләренең күрсәтелгән органнарның вазифаи затларының норматив булмаган хокукый актлары, законсыз карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) гамәлдә түгел дип тану турындагы закон көченә кергән судлар, арбитраж судлар карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау өчен эшче төркем формалаштыру мәсьәләләрен (алга таба – эшче төркем, суд карарлары) һәм эшче төркем утырышларын үткәрү һәм мондый утырышлар нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен җайга сала.

### II. Эшче төркемне оештыру һәм эш тәртибе

2.1. Эшче төркем рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм эшче төркем әгъзалары составында кимендә 7 кеше тәшкил итә. Эшче төркем составына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затлар кертелә.

Эшче төркем составы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

2.2. Хисап кварталында суд карарлары турында мәгълүмат кергән очракта, эшче төркемнең эше хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр үткәрелә торган утырышларда, гамәлгә ашырыла.

Эшче төркем утырышына чакырылалар:

Карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү өчен, суд тарафыннан гамәлдә түгел дип танылган акт, карар кабул итү, гамәлләр кылу (гамәл кылмау) (алга таба – башка хезмәткәрләр) проектын эшләүдә катнашкан Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, шулай ук аның составына керүче җирлекләрнең структур бүлекчәләре хезмәткәрләре;

акт, карар, гамәлләр (гамәл кылмау) белән хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган затлар яки аларның вәкилләре (алга таба – башка затлар);

иҗтимагый оешмалар, район прокуратурасы вәкилләре;

2.3. Суд карарлары турында мәгълүмат мондый карарларның кушымта күчермәләре белән, әгәр хисап кварталында тиешле карарлар чыгарылса, Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм аның составына керүче җирлекләрнең структур бүлекчәләре тарафыннан эшче төркем рәисенә квартал саен хисап кварталыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча җибәрелә.

Мәгълүмат түбәндәге юнәлешләрне үз эченә алырга тиеш:

Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм әлеге органнарның вазифаи затларының норматив булмаган хокукый актлар чыгару, суд тарафыннан гамәлдә түгел (законсыз) дип танылган карар кабул итү һәм гамәлләр кылу (гамәл кылмау) нигезләре;

Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының (аның составына керүче җирлекләрнең) һәм күрсәтелгән органнарның вазифаи затларының норматив булмаган хокукый актларны, законсыз карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмау) дөрес түгел дип тану нигезләре;

башка хезмәткәрләрнең хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карауда катнашу.

Чыгарылган суд карарлары турында мәгълүмат белән бергә аларның кушымта күчермәләрен теркәп, норматив булмаган хокукый актны кабул иткән яки әзерләгән, суд тарафыннан аның гамәлләре сәбәпләренә карата гамәлдә түгел (законсыз) дип танылган карар һәм гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) вазифаи затның (хезмәткәрнең) эш язмалары җибәрелә.

2.4. Эшче төркем рәисе хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр эш төркеме утырышын үткәрү датасын һәм утырышка башка хезмәткәрләрне һәм башка затларны чакыру кирәклеген билгели.

2.5. Эшче төркем секретаре эшче төркем әгъзаларын һәм утырышка чакырылган башка хезмәткәрләрне һәм башка затларны эшче төркем утырышын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә.

Суд тарафыннан гамәлдә түгел (законсыз) дип танылган гамәлләр кылган (гамәл кылмаган), норматив булмаган хокукый акт чыгаруда катнашкан эшче төркем әгъзалары эшче төркем утырышына чакырылмыйлар.

2.6. Эшче төркем утырышы, әгәр анда эшче төркем составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы булып тора. Утырыш рәис тарафыннан үткәрелә, ә ул булмаганда – эшче төркем рәисе урынбасары тарафыннан.

2.7. Хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау барышында эш төркеме:

- суд карарларын, шул исәптән норматив булмаган хокукый актны, Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләренең һәм күрсәтелгән органнарның вазифаи затларының законсыз карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) гамәлдә түгел дип тану нигезләрен анализлый;

- ачыклый:

норматив булмаган хокукый актны чыгару мотивлары һәм шартлары, суд тарафыннан гамәлдә түгел (законсыз) дип танылган карар кабул итү һәм гамәлләр кылу (гамәл кылмау);

норматив булмаган хокукый акт проектларын, карар әзерләүдә катнашкан затларның гамәлләрендә, шулай ук суд тарафыннан гамәлдә түгел (законсыз) дип танылган гамәлләр кылуында (гамәл кылмавында) коррупциячел күренеш билгеләре барлыгы (юклыгы), шул исәптән:

эшләүдә, шулай ук суд тарафыннан гамәлдә түгел дип танылган акт, карарлар һәм гамәлләр кылу (гамәл кылмау) проектын килештерүдә катнашкан затларның шәхси кызыксынуын (мәнфәгатьләр конфликты ситуациясен) күрсәтүче хәлләр;

акт чыгару, карар кабул итү, гамәлләр кылу (гамәл кылмау) белән кызыксынучы затларның коррупциячел тыкшыну очраклары, башка явыз ният белән файдалану очраклары турында шул затларның хәбәр итмәвен күрсәтүче хәлләр;

хокукый актларны бастырып чыгаруны кисәтүгә, шулай ук законга туры килми торган карарлар кабул итүгә һәм гамәлләр кылуга (гамәл кылмауга) юнәлтелгән чаралар һәм коррупцион күренешләр турында тәкъдимнәр эшләп чыгара.

2.8. Югарыда күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча эшче төркем коррупцион күренешләрнең булу (булмау) аның составына керүче авыл җирлекләренең кылмауны) кисәтүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр хәзерли.

2.9. Әлеге Тәртипнең 2.7, 2.8 пунктларында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча эшче төркем карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышларның тигезлеге очрагында, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

2.10. Утырыш нәтиҗәләре буенча эшче төркем секретаре һәм рәисе кул куйган беркетмә төзелә. Беркетмәдә, кабул ителгән карардан тыш, күрсәтелә:

утырыш датасы, утырышны үткәрү вакыты һәм урыны;

утырышта катнашучы эшче төркем әгъзалары;

башка хезмәткәрләр;

утырышта чыгыш ясаучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм чыгышларның төп тезислары, күрсәтелгән тәкъдимнәр;

тавыш бирү нәтиҗәләре;

кабул ителгән карар.

Беркетмәгә суд карарлары күчермәләре, суд тарафыннан дөрес түгел дип танылган норматив булмаган актлар, шулай ук эшче төркемнең карау предметы булган башка материаллар теркәлә.

Утырыш беркетмәсе, шулай ук суд тарафыннан дөрес түгел дип танылган норматив булмаган акт, суд карары Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырылырга тиеш.

2.11. Эшче төркем рәисе утырыш уздырылган көннән алып 5 көннән дә соңга калмыйча Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органы (аның составына керүче җирлек) җитәкчесенә беркетмә җибәрә, аңа (аның вазифаи затларына карата) эшче төркем тиешле карарлар кабул итү өчен хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карап тикшерү йомгаклары буенча тәкъдимнәр бирә.

2.12. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм күрсәтелгән органнарның вазифаи затларының карарларында һәм гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) коррупция өлеше ачыкланган очракта, эшче төркем рәисе эш төркеменең карау предметы булган беркетмәне һәм башка материалларны коррупциягә каршы профилактика һәм булдырмау буенча алга таба чаралар эшләү өчен хезмәт (вазифаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия каравына җибәрә.

Аппарат җитәкчесе В.Н. Фәизов

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгының
29.10.2018 ел, 132 санлы
карарына кушымта №2

Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләренең һәм аның вазифаи затларының норматив булмаган хокук актларын гамәлсез , карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмау) законсыз дип тану турында законлы көченә кергән суд карарлары, арбитраж суд карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау буенча эшче төркем составы (килешү буенча)

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Смирнов П.А. | муниципаль районның башкарма комитетының эшләре белән идарә итүче, эшче төркем рәисе; |
| 2. | Рылов О.Ю. | муниципаль район Башлыгының ярдәмчесе , эшче төркем рәисе урынбасары; |
| 3. | Ефимов Р.М. | муниципаль район Башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы, эшче төркемнең сәркәтибе; |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 4. | Әскәров А.Г | муниципаль район Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы; |
| 5. | Габдрахманов И.Н | муниципаль район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы; |
| 6. | Мәхмүтова И.Ю. | муниципаль район Советының муниципаль хезмәт һәм кадрлар белән эшләү секторы мөдире; |
| 7. | Нәфиков Т.Г. | муниципаль район Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| 8. | Смирнов А.П. | муниципаль район Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| 9. | Спиридонов С.П. | муниципаль район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| 10. | Юнысова Г.Х. | муниципаль район Советының оештыру эшләре бүлеге башлыгы; |

Муниципаль район Советы
аппараты җитәкчесе В.Н.Фәизов